**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

28.10.2019 | Казан шәһәре | № 343

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

**б о е р а м :**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрүнең теркәлә торган Тәртибен расларга.

2. Юридик һәм мобилизация эше секторына әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алуга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне министр урынбасары А.М.Миңгуловка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы

Спорт министрлыгының

2019_28.10 нән 343номерлы

боерыгы белән расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫНА ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Министрлык эшли торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза 2009 елның 17 июленнән 172 номерлы «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февраленнән «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 96 нчы номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабреннән «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 883 нче карары, 2017 елның 15 августыннан «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза тәэмин итүнең һәм аларны әзерләгәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуның өстәмә гарантияләре турында» 2017 елның 29 июненнән ПУ-575 номерлы Указын гамәлгә ашыру чаралары турында» 580 номерлы карары, шулай ук әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм акт проектларында коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба юкка чыгару тора.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчен югалткан яисә юкка чыгарылган норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

## II. АКТЛАРГАҺӘМ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ

2.1. Актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкта коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат (алга таба – вазыйфаи зат) тарафыннан үткәрелә. Күрсәтелгән вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) алып бару өчен җаваплы (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта).

Вазыйфаи зат Татарстан Республикасы спорт министры тарафыннан билгеләнә (алга таба – министр).

2.2. Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен актлар һәм актлар проектлары әлеге акт (акт проектын эшләү өчен җаваплы) аның инициативасы буенча кабул ителгән структур бүлекчәнең җитәкчесе тарафыннан вазыйфаи затка җибәрелә.

2.3. Коррупциягә каршы экспертиза Журналда акт теркәлгәннән соң ун көн эчендә үткәрелә.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча бәяләмә төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага тәкъдим ителгән акт реквизитлары (акт проектының атамасы);

актта (акт проектында) коррупциячел факторлар булу яисә булмау;

актның (акт проектының) коррупциячел факторлар булган конкрет нигезләмәләре (алар булганда);

акт (акт проекты) нигезләмәләрен үзгәртү я коррупциячеллекне юкка чыгару өчен (коррупциячел факторларны ачыкланганда) аерым нигезләмәләрне төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр.

2.5. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән һәм вазыйфаи зат тарафыннан әзерләнгән һәм имзаланган бәяләмә төзелгән көнне әлеге актны (акт проектын) җибәргән структур бүлекчәгә тапшырыла.

2.6. Министрлыкның акт (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелгән бәяләмәне алгач, министр белән килештереп, өч көн эчендә аларны норматив хокукый акт проектын эшләп бетергәндә исәпкә ала һәм эшләнеп беткән норматив хокукый акт проектын вазыйфаи затка кабат карауга җибәрә.

Экспертизага җибәрелгән актта (акт проектында) коррупциячел факторлар булмаса, актны (акт проектын) эшләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, кызыксынучы структур бүлекчәләрнең җитәкчеләре визалары белән актны (акт проектын) министрга кул куярга җибәрә яисә акт (акт проектын) кызыксынган органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрүне тәэмин итә.

## III. АКТЛАР ҺӘМ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БӘЙСЕЗ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ

3.1.Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып Министрлыкның рәсми бастырылган һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында http://minsport.tatarstan.ru (алга таба – сайт) яисә аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм җәмәгатьчелек фикер алышуын уздыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ Интернет-портал тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнарына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм җәмәгатьчелек фикер алышуын (алга таба – бердәм региональ интернет-портал) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында (http://tatarstan.ru/regulation) урнаштырылган норматив хокукый актлары, Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары тора.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр яки конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

3.2. Закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына кертелә торган Министрлык эшли торган федераль закон проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен Министрлык аларны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында һәм бердәм региональ интернет-порталда аларны килештерүгә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынган башкарма органнарына, башка органнарга һәм оешмаларга юлланган эш көне дәвамында урнаштыра.

3.3. Министрлык актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, акт проектын әзерләү өчен җаваплы министрлыкның структур бүлекчәсе, акт проектын карау өчен вазыйфаи затка җибәрү көненә туры килә торган эш көне дәвамында, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын) күрсәтеп, сайтта һәм бердәм региональ интернет-порталда акт проектын, шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын урнаштыра.

3.4. Сайтта урнаштырылган акт проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты аны урнаштыру көненнән алып биш эш көненнән дә кимрәк булмаган вакытны тәшкил итә.

3.5. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча) Министрлыкка вакыт чикләрендә кергән бәяләмә (алга таба – бәяләмә, ул кергән көннән соң килгән эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм карау өчен министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә җибәрелә.

3.6. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим итү характерына ия. Министрлык коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәне, әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, аны теркәгән көннән алып 15 көн эчендә мәҗбүри карарга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яисә физик затка дәлилләнгән җавап (бәяләмәдә ачыкланган коррупциячел факторлар турында мәгълүмат яисә ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш) җибәрелә, анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу һәм (яисә) норматив хокукый актта яисә норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциячел фактор белән килешмәү сәбәпләре чагылыш таба.

3.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр:

норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формага туры килмәгән очракларда карап тикшерелмиләр.

Әлеге Тәртипнең 3.7 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очракта Министрлык мондый бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлгән көннән алып 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтара.

3.8. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциячел факторлар эшләүчеләр тарафыннан акт проектын эшләп бетерү стадиясендә юкка чыгарыла.

Проектны эшләүче тарафыннан акт проектына коррупциягә каршы экспертиза үткәргәннән соң үзгәрешләр кертелгән очракта акт проекты кабат коррупциягә каршы экспертиза узарга тиеш.

3.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кимчелекләрне юкка чыгарганнан һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне теркәп, кабат карау өчен вазыйфаи затка тапшыра. Кабат карау өч

көн эчендә башкарыла.

3.10. Әгәр актта коррупциячел факторлар ачыкланса, Министрлыкның әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе Министрлыкта бәяләмәне теркәгән көннән соң өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аның үз көчен югалтуын тану турында чаралар күрә.

3.11. Әзерләүче ул эшләгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасына кертелә торган федераль законнар проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторлар булуын дәлилли торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, эшләүче күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентында билгеләнгән тәртиптә, коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза бәяләмәсен, һәм үзенең ризасызлыгын нигезләгән аңлатма язуларын теркәп, карау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

## IV. НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ФИКЕРЕН БЕЛҮ

4.1. Министрлык эшләнә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итә.

4.2. Җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында норматив хокукый актлар проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза һәм җәмәгатьчелек фикер алышуы уздыру өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актлары проектларын урнаштыру өчен бердәм региональ интернет-портал белән билгеләнгән Татарстан Республикасының рәсми порталында (http://tatarstan.ru/regulation) (алга таба – Мәгълүмат ресурсы) урнаштырыла.

4.3. Җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү өчен Мәгълүмат ресурсында гражданнарның хокуклары, ирекләре һәм бурычларына кагылышлы норматив хокукый актлар проектлары урнаштырыла.

4.4. Җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында:

дәүләт серен тәшкил итә торган яисә конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар проектлары;

актларны (аларның структур берәмлекләрен) үз көчләрен югалткан дип тану турында норматив хокукый актлар проектлары;

эшләү вакыты Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Премьер-министры һәм аның урынбасарлары йөкләмәләрендә билгеләнгән иҗтимагый фикер алышуның минималь вакытыннан кимрәк булган

норматив хокукый актлар проектлары (Мәгълүмат ресурсында урнаштырган көннән биш эш көненнән дә кимрәк);

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә яисә чыгымнарына йогынты ясый торган норматив хокукый актлар проектлары, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә бәйле норматив хокукый актлар проектлары;

террорчылык, шул исәптән террорчылыкны финанслау белән көрәш буенча чараларны тормышка ашырганда дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген һәм хезмәттәшлеген оештыру, тәэмин итү мәсьәләләрен көйли торган норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән норматив хокукый актлар проектлары;

суд карарларын, прокурорлык реакциясе актларын, тикшерү-хисап органнары күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру максатларында әзерләнгән норматив хокукый актлар проектлары;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары һәм дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентлары проектлары;

статистик күзәтү формаларын раслау турында норматив хокукый актлар проектлары;

Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының гамәлдә булуын туктатып тору турында норматив хокукый актлар проектлары урнаштырылмыйлар.

4.5. Җәмәгатьчелек фикер алышуын тәэмин итү өчен норматив хокукый актлар проектларын урнаштырганда, аның инициативасы буенча проект эшләнгән структур бүлекчә тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы), шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуы башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтә.

4.6. Эшләүче тарафыннан билгеләнә торган норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы вакыты Мәгълүмат ресурсында урнаштырылган көннән алып биш эш көненнән дә кимрәк булмаска тиеш.

4.7. Әгәр аның инициативасы буенча проект эшләнгән структур бүлекчә җәмәгатьчелек фикер алышуы нәтиҗәләре буенча норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү турында карар кабул итсә, эшләнеп бетерелгән норматив хокукый акт проекты шулай ук җәмәгатьчелек фикер алышуы максатларында урнаштырыла.

4.8. Мәгълүмати ресурста норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты, җәмәгатьчелек фикер алышуы вакыты тәмамланганнан соң 30 көн эчендә актның (акт проектының) җаваплы әзерләүчесе коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү барышында ачыкланган коррупциячел факторлар, иҗтимагый фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәр турында, әлеге Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендә аларны карау нәтиҗәләрен чагылдырып, җыелма мәгълүмат урнаштыра.

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
норматив хокукый актлары һәм
норматив хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибенә 1 нче кушымта

КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗАГА КЕРГӘН НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛУ ЖУРНАЛЫ

| | Актның (акт проекты-ның) экспертиза-га керү датасы | Актны (акт проектын) тәкъдим иткән структур бүлекчә | Актның (акт проектының) атамасы | Коррупциячел нормаларның булу/булмавы | Бәяләмә төзү датасы | Искәрмә (кабат экспертиза уздыру турында мәгълүмат, кабат экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү датасы) (акт проектларына карата) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
норматив хокукый актлары һәм
норматив хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибенә 2 нче кушымта

КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА
БӘЯЛӘМӘСЕ

__________________________________________________________________________

(норматив хокукый акт реквизитлары яки норматив хокукый акт проекты

__________________________________________________________________________

атамасы)________________________________________________________________

2003 елның 17 июленнән «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 172-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабреннән «Аерым норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 883 номерлы карары белән расланган аерым норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе буенча, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февраленнән «Норматив хокукый актлар һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 96 нчы номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә анда коррупциячел факторларны ачыклау һәм аларны алга таба юкка чыгару максатында актка коррупциягә каршы экспертиза уздырылды.

Проектта корупциячел факторларның булуы яки булмавы:

__________________________________________________________________________

Акт проектының коррупциячел нормалар булган конкрет нигезләмәләре:

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Коррупциячеллекне юкка чыгару өчен формулировкаларны үзгәртү яисә аерым нормаларны бетерү буенча тәкъдимнәр:

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

Вазыйфаи зат __________________ ____________________

(имза) (Ф.И.Аи.)

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
норматив хокукый актлары һәм
норматив хокукый актлары проектларына
коррупциягә каршы экспертиза
үткәрү тәртибенә 3 нче кушымта

ПРОЕКТНЫ КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ БӘЙСЕЗ ЭКСПЕРТИЗА ҺӘМ (ЯКИ) ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕК ФИКЕРЕН БЕЛҮ ЙОМГАКЛАРЫ БУЕНЧА ҖЫЕЛМА МӘГЪЛҮМАТ

____________________________________________________________________
(норматив хокукый акт төре, норматив хокукый акт проекты атамасы)

| Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза | | | |
|---|---|---|---|
| № | Эксперт (Ф.И.Аи. (соңгысы – булганда)/аккредитация турында карар реквизитлары) | Ачыкланган коррупциячел фактор | Эшләүче комментарийләре |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Җәмәгатьчелек фикер алышуы | | | |
| № | Фикер алышуда катнашучы (Ф.И. Аи. (соңгысы – булганда) / электрон почта адресы) | Фикер алышуда катнашучының позициясе | Эшләүче комментарийләре |
| | | | |
| | | | |
| Кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Өлешчә исәпкә алынган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |
| Исәпкә алынмаган тәкъдимнәрнең гомуми саны | | | |